ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

14 ноябрь 2025ел

№ 9166

Башкарма комитетның 2025 елның 4 июлендәге 4903 номерлы Карары белән расланган махсус хәрби операция ветераннары, анда катнашучылар һәм аларның гаиләләре белән эшләр оештыруга, шулай ук халыкны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатында муниципаль учреждениеләр булып тормаган коммерцияле булмаган оешмаларга Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2025 елның 4 июлендәге 4903 номерлы Карары белән расланган махсус хәрби операция ветераннары, анда катнашучылар һәм аларның гаиләләре белән эшләр оештыруга, шулай ук халыкны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатында муниципаль учреждениеләр булып тормаган коммерцияле булмаган оешмаларга Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, 6 пунктны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«64. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы, аларга ихтыяҗ булмаганда, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көнендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

Субсидия калдыгына ихтыяҗ булганда, Алучы агымдагы елның 15 декабренә кадәр Башкарма комитет адресына әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган максатларда чираттагы финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгыннан файдалану турында мөрәҗәгать җибәрә.

Алучының агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидияләр калдыгына ихтыяҗы, мөрәҗәгать кергән көннән башлап биш эш көне эчендә үткәрелә торган комиссия утырышында карап тикшерелә.

Субсидия калдыгы Алучы тарафыннан, комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган максатларга җибәрелә.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында каралган нигезләмәләр субсидия бирү турындагы килешүдә карала.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов